# КАРАР

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Елаур авыл җирлегенең Октябрина поселогы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**13 октябрь 2023 ел** **№ 3**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2023 елның 13 октябрендә узган «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Елаур авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидтан тыш, 2024 елда 2000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

Октябрина торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге авыл эчендәге юлларны ремонтлау (юл полотносын күтәрү, сатып алу, ташу, вак таш җәю, транспорт хезмәтләре)
роторлы чапкыч сатып алу мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 54 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 41 кеше катнашты.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 41 кеше тавыш бирде;
«ЮК» позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:
1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Елаур авыл җирлегенең Октябрина поселогы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Елаур авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидтан тыш, 2024 елда 2000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

Октябрина торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге авыл эчендәге юлларны ремонтлау (юл полотносын күтәрү, сатып алу, ташу, вак таш җәю, транспорт хезмәтләре)
роторлы чапкыч сатып алу мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарны танырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында» http://pravo.tatarstan.ru., Нурлат

муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/, мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Елаур авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: О.В.Охотникова

Елаур авыл җирлеге башлыгы О.В.Охотникова